МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ

Федеральное государственное автономное образовательное учреждение высшего образования

«Казанский (Приволжский) федеральный университет»

УТВЕРЖДАЮ

Проректор по образовательной деятельности

_______________ Д.А.Таюрский

«15» марта 2017г.

# ПРОГРАММА ВСТУПИТЕЛЬНОГО ИСПЫТАНИЯ ПО СПЕЦИАЛЬНОСТИ

для поступающих на программы подготовки научно-педагогических кадров в аспирантуре

**Направление 44.06.01 Образование и педагогические науки**

*Направленность (профиль): 13.00.02 - Теория и методика обучения и воспитания (татарскому языку и литературе)*

Казань 2017

# Татар теле укыту методикасы
## П р о г р а м м а

### Мәктәптә татар телен фән буларак укыту методикасы

Методика фәненең өйрәнү предметы һәм бурычлары, аның башка фәннәр арасында тоткан урыны.

Татар теле укыту методикасының тел белеме, психология, педагогика, сөйләм эшчәнлеге теориясе һәм логика кебек фәннәр белән бәйләнеше.

Татар теле укыту методикасының гомумдидактик принциплары һәм фәнни-тикшерену методлары. Алдынгы мәктәп һәм укытучыларның эш тәҗрибәләрен өйрәнүнең методика фәнендәге урыны.

Методиканың үсеш тарихына күзәтү. Татар теле укыту методикасында мәгърифәтче-галим К.Насыйри эшчәнлеге.

Рус һәм татар телләрендә язылган беренче татар грамматикаларының методика үсешендәге әһәмияте (А.Троянский, Г.Фәезханов, И.Хәлфин, Җ.Вәлиди, Г.Ибрагимов һ.б.).

XX йөздә татар телен укыту методикасы өлкәсендә эшләгән галимнәрдән Г.Лотфи, М.Галләмова, М.Фазлуллин, Ф.Вәлиева, С.Вәгыйзов һәм Р.Вәлитова һ.б. хезмәтләре.

Бүгенге көндә мәгариф учреждениеләрендә татар телен укытуның торышы, аның тәрбияви әһәмияте.

### Татар телен укыту формалары

Укытуны оештыруның төп формасы буларак дәрес. Аны үткәрүгә төп таләпләр. Хәзерге вакытта үткәрелә торган дәресләрнең типлары, төзелеше, төрләре һәм формалары.

### Татар теле укыту чаралары

Татар теле программаларының төзелү тарихына күзәтү.

Программаларның төзелү принциплары, аларның төп бүлекләре. Татар теле программаларында укучыларның белем, осталык һәм күнекмәләренә таләпләр.

Татар теле дәреслекләренең төзелү тарихына күзәтү.

Дәреслекләрнең төзелү принциплары, аларга куела торган методик таләпләр.

Татар телен укыту чаралары буларак кулланмалар, журналлар, рәсемнәр, таратма материаллар, күрсәтмә әсбаплар, алардан дәресләрдә нәтиҗәле файдалану юллары. Тел дәресләрендә заманча укыту чараларының тоткан урыны (видеомагнитофон, компьютер программалары).

Тел укытуның нигезен тәшкил итә торган чаралардан дәрестән тыш эшләр (түгәрәкләр, татар теле атналыгы һәм олимпиада үткәрү һ.б.). Аларны уздыру максатлары, әһәмияте, төрләре һәм формалары.

Укыту чарасы буларак татар теле кабинеты. Аны оештыруга методик таләпләр. Тел кабинетының паспортын төзү. Кабинетны җиһазлау, аның эшчәнлегендәге төп юнәлешләр.

Татар телен укыту чараларыннан төрле типтагы сүзлекләр һәм алардан дәресләрдә нәтиҗәле итеп файдалану (телара, аңлатмалы, этимологик, энциклопедик һ.б. сүзлекләр).

### Телебезнең фонетикасын, сүз ясалышын һәм төзелешен, лексикасын һәм грамматикасын укыту методикасы

Тел бүлекләрен укыту мирасына күзәтү. Аларны өйрәтүнең бурычлары һәм әһәмияте. Укучыларны тел һәм сөйләм эшчәнлегенә өйрәтүнең бердәмлеге, аның гамәли максатка ярашлы итеп алып барылуы. Татар телен укытуның тел белеменә нигезләнүе. Тел материалының программа һәм дәреслекләрдә бирелү принциплары.

Гамәлдәге программа һәм дәреслекләргә гомуми характеристика. Аларның рус мәктәпләре өчен төзелгәннәреннән аермалы яклары.

Мәктәптә телебезнең *фонетикасын* һәм *графикасын* укытуның әһәмияте. Сүздәге аваз һәм хәрефләрне аера белү күнекмәләре булдыру һәм аларны үстерү. «Аваз», «хәреф», «иҗек», «басым», «интонация», «пауза» кебек төшенчәләрне үзләштерү эшен үткәрү методикасы. Укучыларда сузык һәм тартык авазларны аеру, яңгырау һәм саңгырау тартыкларны, сүз басымын дөрес билгеләү һәм әйтү, сүзләрне иҗеккә бүлү, сүз, сүзтезмә, җөмлә һәм текстларны тиешле интонация белән уку күнекмәләре булдыру һәм аларны үстерү өстендә эшләү.

Татар теленең просодик системасы турында мәгълүмат биреп, телебездәге синтагмаларның төзелү үзенчәлекләрен барлау, аларны укучыларга җиткерү методикасы.

Татар телендә сүз һәм фраза басымы, аларның әһәмияте һәм сөйләмдә дөрес кулланылышы. Төрле сүз төркемнәрендә һәм җөмләләрдә басымны тиешенчә куярга өйрәтүнең метод һәм алымнары.

Татар теленең интонацион төзелмәләре, аларның үзенчәлекләрен дөрес куллану күнекмәләрен булдыру.

Тел дәресләрендә орфоэпик сүзлекләрдән файдалану алымнары.

Фонетика өлкәсендә эшләгән галимнәрнең хезмәтләренә күзәтү.

Татар алфавитын үзләштерү һәм кирәкле урында аны тиешенчә файдалана белү күнекмәләре булдыру һәм үстерү.

Сүзләргә фонетик анализ ясау күнекмәләре булдыру.

*Сүз төзелеше* һәм *сүз ясалышы* буенча алган гомуми мәгълүматны гамәли эштә файдалана белү күнекмәләрен үстерү. Татар телендәге сүзләрнең мәгънәле кисәкләреннән тамыры, кушымчалары һәм нигезе турындагы белемнәрне сүз төзелешен тикшергәндә файдалану. Кушымчаларны ясагыч һәм мөнәсәбәт белдерүчеләр дип бүлүнең фәнни яктан дәлилләгән булуы. Модальлек һәм бәйләгеч кушымчаларның аерым сүз төркемнәренә беркетелгән булуы.

Татар телендәге сүз ясалыш ысулларын төркемләү, аларга гомуми характеристика. Мәктәптә сүз ясалышына караган терминнарны файдалану мәсьәләсе.

Синтетик һәм аналитик структуралы сүзләр. Ясагыч һәм ясалган сүзләрнең үзара мөнәсәбәте. Тамырдаш сүзләр мәсьәләсе. Телебездәге сүзләрнең ясалыш мәгънәсе. Татар телендәге ясалма сүзләрне барлау методикасы.

Сүз төзелешен һәм ясалышын тикшерүгә багышланган күнегүләрне төзү һәм аларны үткәрү үзенчәлекләре.

Башлангыч, урта һәм югары сыйныфларда сүз ясалышын һәм төзелешен укыту методикасына төп таләпләр. Бу эшнең турыдан-туры морфология ягъни аерым сүз төркемнәрен өйрәнүгә бәйле булуы.

Сүз төзелешен һәм ясалышын тикшерүгә багышланган күнегүләрне үтәү методикасы.

Татар теле дәресләрендә укучыларның *сүз байлыгын* үстерү буенча эшләү методлары һәм алымнары. Сүзләрне кулланылу өлкәсе һәм ешлыгына карап төркемләүнең сөйләм үстерүдәге әһәмияте, бу вакытта укытучы алдына куела торган методик таләпләр.

Тел дәресләрендә синоним, антоним һәм омонимнарны өйрәнү. Алынма сүзләрне үзләштерү һәм аларны сөйләмдә дөрес куллану күнекмәләре тәрбияләү максатыннан чыгып төзелгән күнегүләр системасы. Тотрыклы сүзтезмәләрне ирекле сүзтезмәләрдән аеру һәм аларны дөрес кулланырга өйрәтү.

Тел дәресләрендә синонимнар, антонимнар, тәрҗемә һәм аңлатмалы сүзлекләр белән эшләү методикасы.

Сүзләргә лексик анализ ясау, сөйләмдә лексик хаталарны булдырмау максатыннан чыгып төзелгән күнегүләр системасы. Лексикология өлкәсендә эшләгән галимнәр эшчәнлеге.

Укучыларда *грамматик* төшенчәләренең формалашу үзенчәлекләре. Башлангыч, урта һәм югары сыйныфларда укучыларга грамматика укытуның үзенчәлекләре.

Грамматиканың бер өлеше буларак, *морфологияне* укыту, аның төп төшенчәләрен үзләштерүдәге кыенлыклар.

Сүзләрне төркемләүгә карата булган карашлар төрлелеге һәм хәзерге тел белемендә бу мәсьәләнең куелышы.

Мөстәкыйль мәгънәле сүз төркемнәреннән *исем,* аны төрле (башлангыч, урта һәм югары) сыйныфларда укыту методикасы. Исемнәргә билгеләмә бирүдә аның лексик-грамматик, морфологик һәм синтаксик билгеләрен бергә карауның әһәмиятен төшендерү.

Сан категориясен өйрәнүдә мәгънә үзенчәлекләренең төрле төркемчәләргә кергән исемнәрдә төрлечә булуын аңлату методикасы.

Тартым категориясенең үзенчәлекле күренеш буларак мәгънәләрен һәм белдерелү юлларын өйрәтү алымнары.

Килеш категориясе системасына төшендерү. Бу категория турындагы фикерләрнең төрлелегенә методик күзлектән чыгып бәя бирүнең әһәмияте.

Телебездәге тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнешендәге үзенчәлекләрне укыту методлары һәм алымнары.

Төрле сыйныфларда исемнәргә морфологик анализ ясауның эзлеклелеге һәм дәвамлы булуы. Морфологик анализны үткәрү методикасы.

Татар телендәге исемләшү күренеше. Исемләшү белән төрле сүз төркемнәреннән исем ясалуны (конверсия һ.б. ысулларны) аеру алымнары.

Исемнән башка сүз төркемнәренең килеш һәм тартым белән төрләнү очраклары.

Башлангыч, урта һәм югары сыйныфларда сыйфатларны өйрәтү. Алардагы лексик–грамматик, морфологик һәм синтаксик билгеләрнең үзенчәлекләрен ассызыклау.

Урта сыйныфларда сыйфат төркемчәләрен укытуның метод һәм алымнары.

Сыйфатларның исемләшү очраклары.

Сыйфатларга морфологик анализ ясау методикасы. Төрле сыйныфларда аны үткәрү эзлеклелеге.

Рәвешләрнең лексик-грамматик, морфологик һәм синтаксик билгеләре. Рәвешләрне төркемләүне методик яктан нигезләү.

Рәвешләр белән урын-ара килешләренең мәгънәләрендәге уртаклык нәтиҗәсе буларак, аларның конверсия ысулы белән ясалуы.

Рәвешләрне укытуда аларны сыйфатлар белән чагыштыруның методик алым буларак өстенлеге.

Рәвешләргә морфологик анализ ясауны үткәрү методикасы.

Саннарның лексик-грамматик, морфологик һәм синтаксик билгеләрен төшендерү. Аларның исемнәрдәге сан категориясеннән аермасы. Татар телендә сан белән саналмыш мөнәсәбәте. Исемнәр алдыннан килгән күплек төшенчәсен белдерә торган сүзләр группасына күзәтү ясау.

Сан төркемчәләрен укыту алымы буларак, аларны үзара чагыштыру һәм белдерелү формаларына аерым игътибар бирү. Бу уңайдан тәртип, чама һәм җыю саннарының үзенчәлекләрен аңлату.

Саннарның исемләшүе.

Саннарга морфологик анализ ясау методикасы.

Сыйфат белән рәвеш һәм сыйфат белән саннарны үзара чагыштырып, аларның уртак һәм аермалы билгеләрен өйрәнү.

Алмашлыкларны үз янәшәсендәге мөстәкыйль мәгънәле башка сүз төркемчәләрен алыштырып килүләре һәм мәгънәләреннән чыгып төркемләүнең методик әһәмияте.

Исемләшә ала торган алмашлыкларны танып, аларга морфологик анализ ясау күнекмәләре тәрбияләү.

Килеш һәм тартым белән төрләнеп, берлек һәм күплек сан формасында килә торган алмашлыкларны барлау һәм аларга морфологик анализ ясау күнекмәләре булдыру.

Фигыльләргә хас булган грамматик категория үзенчәлекләрен чагылдырган алмашлыкларга күзәтү ясау. Аларга морфологик анализ ясау методикасы.

Алмашлыкларның башка сүз төркемнәренә мөнәсәбәтен ачыклау. Аларга тулы морфологик анализ ясау алымнары.

Татар телендә сүзлек байлыгы зур һәм грамматик категорияләрнең күп булуы ягыннан фигыльләргә тулы билгеләмә бирү үзенчәлеге, аны төрле сыйныфларда аңлату методикасы.

Фигыльләрдәге грамматик категорияләрне төркемләүнең методик яктан әһәмияте.

Универсаль грамматик категория буларак, барлык-юклык һәм аны телебездә белдерә торган чаралар системасы.

Лексик-грамматик категория буларак, юнәлеш һәм дәрәҗә, аларны урта һәм югары мәктәптә үзләштерү, өйрәнү алымнары.

Төркемчә төшенчәсенең асылы. Урта һәм югары мәктәптә аны өйрәтү үзенчәлекләре.

Заман һәм зат-сан категорияләрен өйрәтү методлары һәм алымнары.

Боерык һәм шарт фигыльләрне укыту-өйрәтү үзенчәлеге.

Затланышлылардан хикәя фигыль һәм аны укыту алымнары.

Сыйфат фигыльләрне өйрәтүдәге кыенлыклар, аларны булдырмау юллары. Сыйфат фигыльләрне хикәя фигыльләрдән дөрес аеру өчен төзелгән күнегүләр системасы.

Хәл фигыльләрне рәвешләрдән дөрес аеру өчен төзелгән күнегүләр системасының әһәмияте.

Татар телендәге үзенчәлекле форма буларак, исем фигыльләр һәм аларны өйрәтү алымнары. Исем фигыльләрне исемнән дөрес аеру күнекмәләре тәрбияләү.

Конверсия ысулы белән исем фигыльләрнең исемгә күчүе, аларның исемләшүгә мөнәсәбәтен ачыклауның методик әһәмияте.

Инфинитивның башка затланышсыз фигыльләр белән уртаклыгы һәм алардан аермасын дөрес итеп билгеләүнең методик әһәмияте.

Татар телендә ярдәмче фигыльләрнең роле.

Фигыльләргә тулы морфологик анализ ясау алымнарын үзләштерү.

Аваз ияртемнәренең мөстәкыйль сүз төркемнәре арасында тоткан урыны. Укучыларга аның ярдәмлекләрдән аермалы якларын төшендерү.

Бәйләгеч сүз төркемнәренең башка сүз төркемнәре арасындагы урыны. Аларны бер-берсе белән чагыштыруның методик өстенлеге.

Бәйлекләр һәм бәйлек сүзләр белән теркәгеч һәм теркәгеч сүзләргә морфологик характеристика бирү, аларны башка сүз төркемнәреннән аера белү күнекмәләре тәрбияләү.

Модаль мәгънәле сүз төркемнәренең сөйләүченең чынбарлыкка мөнәсәбәтен белдерүен аңлау ягыннан кисәкчә, ымлык, модаль һәм хәбәрлек сүзләрнең сүз төркемнәре арасында тоткан урыны. Аларны төркемләү һәм морфологик анализ ясау күнекмәләре тәрбияләү. Хәбәрлек сүзләрнең мөстәкыйль һәм модаль мәгънәле сүз төркемнәре арасындагы үзенчәлекле урынын аңлату.

Кисәкчәләр, ымлыклар, модаль һәм хәбәрлек сүзләргә морфологик анализ ясау осталыгын булдыру һәм үстерү.

Телебезнең морфологик системасы буенча эшләгән галимнәрнең хезмәтләренә күзәтү.

Грамматиканың бер өлеше буларак *синтаксис,* аны башлангыч, урта һәм югары сыйныфларда укыту методлары һәм алымнары. Синтаксик төшенчәләрнең формалашуы, аларны гамәли эштә тиешенчә куллана белү күнекмәләре тәрбияләү.

Җөмләдә сүзләр бәйләнеше төрләрен һәм аларны барлыкка китерә торган тел чараларына анализ ясарга өйрәтү. Сүзтезмә һәм җөмлә төрләренә характеристика бирү алымнарын үзләштерү.

Җөмлә кисәкләре һәм сүз төркемнәре төшенчәләре белән аңлап эш итү, аларны гамәли эштә бер-берсеннән аера белү.

Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен дөрес билгеләү. Сүзләрнең туры һәм кире тәртибен (инверсия) билгеләү осталыкларын тәрбияләү һәм үстерү.

Җөмләнең аерымланган кисәкләреннән хәл һәм аныклагычларны тиешенчә куллана белү, алар янында тыныш билгеләрен дөрес кую күнекмәләре булдыру.

Җөмләдәге тиңдәш кисәкләр һәм алар янындагы гомумиләштерүче сүзләр янында тиешле тыныш билгеләрен куярга өйрәтү. Кереш сүз, кереш җөмләләрне аерымланган кисәкләрдән аера белү күнекмәләре һәм осталыклары булдыру.

Гади җөмләләргә синтаксик анализ ясау.

Кушма җөмлә синтаксисында үзара тезүле һәм ияртүле бәйләнештә торган җөмләләрне бер-берсеннән аеру, аларга характеристика бирү күнекмәләре булдыру һәм үстерү. Тезүле һәм ияртүле бәйләнешне булдыра торган тел чараларына характеристика бирү.

Синтетик һәм аналитик төзелмәләргә характеристика, аларны белдерә торган тел чараларын дөрес куллану күнекмәләре тәрбияләү.

Иярчен җөмләләрне мәгънәләре ягыннан төркемләү, аларның синтетик һәм аналитик төрләрен дөрес тикшерү, мисаллар китерә белү күнекмәләре.

Күп иярченле катлаулы кушма җөмлә төрләренә гомуми характеристика биреп, аларның схемаларын төзү һәм мисаллар китерү яки әдәби әсәрдән күрсәтелгән схемага туры килгән җөмләләрне табу күнекмәләрен булдыру.

Текст синтаксисы, аның теориясенә караган гомуми мәсьәләләр турында мәгълүмат бирү. Синтаксик бөтеннәр һәм алар составына керүче җөмләләр арасындагы бәйләнешне билгеләү күнекмәләре булдыру. Текстның башламы, тәмамланган булуы, андагы уртак сөйләм һәм модальлекне белдерә торган тел чаралары.

Гади һәм кушма җөмләләргә синтаксик анализ ясау методикасы һәм аны үткәрүдәге кыенлыклар, аларны булдырмау чаралары.

Синтаксис һәм пунктуация. Төрле сыйныфларда пунктуациягә бәйле материалның бирелү күләме. Тел дәресләрендә тыныш билгеләрен дөрес куярга өйрәтү алымнары. Пунктуацион хаталар өстендә эшләү һәм аларны кисәтүгә юнәлтелгән күнегүләр системасы булдыру, аларны үткәрү методикасы.

**Укучыларның сөйләм телен үстерү методикасы**

Тел дәресләрендә сөйләм телен үстерүнең психологик – лингвистик нигезләре. Сөйләм эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү.

Укучыларның сөйләм эшчәнлеген камилләштерүнең лингвистик нигезләре. Сөйләм үстерүдә текст белән эшләүнең әһәмияте (җөмләне актуаль кисәкләргә һәм «кызыл юл» буенча бүлү).

Текстның үзенчәлеген чагылдыруы ягыннан сөйләм типлары (хикәяләү, тасвирлау, фикер йөртү һ.б.ш.).

Укучыларның сөйләм телен үстерү максатыннан, аларны тыңларга һәм укырга өйрәтү методикасы.

Сөйләм культурасына өйрәтүдә күзәтелә торган кыенлыклар, аларны булдырмау юллары. Сөйләм этикеты мәсьәләләре.

Бәйләнешле сөйләмне үстерүдә язма эшләрнең әһәмияте.

Төрле характердагы изложение һәм сочинениеләрне үткәрү методикасы.

Укучыларның сөйләм телен үстерү максатыннан чыгып, эш кәгазьләре язарга өйрәтү.

Бәйләнешле сөйләм телен үстерү дәресләренә карата куела торган методик таләпләр.

Язма һәм телдән сөйләм хаталарын төзәтү һәм аларны кисәтү өчен төзелгән күнегүләр системасына таләпләр.

## Орфографик күнекмәләр булдыру һәм аларны үстерү методикасы

Орфографиягә өйрәтүнең максаты, бурычлары һәм әһәмияте. Татар теленең орфографик кагыйдәләр җыелмасын башлангыч, урта һәм югары сыйныфларда өйрәнү эзлеклелеге. Шуңа бәйле рәвештә төзелгән орфографик күнегүләрне системалы рәвештә үтәү – грамоталы язуның нигезе.

Орфограмма төшенчәсе белән кагыйдәләр арасында бәйләнеш һәм алар арасындагы аерма.

Татар орфографиясенең принциплары. Телебезнең фонетик принцибы-орфографиягә нәтиҗәле итеп өйрәтүнең нигезе.

Тел дәресләре өчен орфографик биремнәр (күнегүләр) төзү һәм аларны үтәүгә булган методик таләпләр.

Типик орфографик хаталар һәм аларны кисәтү алымнары. Хаталар өстендә эшләү методикасы.

Орфографиягә өйрәтү алымнары, аларны үткәрү методикасы.

Тел дәресләрендә орфографик сүзлекләрдән файдалану.

## Әдәбият


Амонашвили Ш.А. Воспитательная и образовательная функция оценки учения школьников. – М, 1984.

Биктаһиров К.Л. Татар теле фонетикасын укыту. – Казан, 1971.

Богоявленский Д.Н. Психология усвоения орфографии. – М., 1966.

Вәгыйзов С.Г., Вәлитова Р.Г. Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы. – Казан, 1996.

Вәлиева Ф.С. М.Х.Корбангалиевның татарларга һәм татар булмаганнарга татар теле укыту буенча методик системасы: Дис. ... канд. пед. наук. - Казан, 1951.

Вәлиева Ф.С. Татар теле дәресләрендә техник чаралардан файдалану.–Казан: Тат. китап нәшр., 1972–.45 б.

Вәлиева Ф.С. Татар теле дәресләрендә укучыларның танып белү эшчәнлеген активлаштыру. – Казан, 1975.

Вәлиева Ф.С., Саттарова Г.Ф. Урта мәктәптә татар телен укыту методикасы. – Казан, 1978.

Вәлиева Ф.С., Саттарова Г.Ф. Урта мәктәп һәм гимназияләрдә татар телен укыту методикасы. – Казан, 2000.

Галләмова М.Ш. Башлангыч мәктәптә татар теле методикасы. – Казан, 1950.

Дмитриев Н.К. и др. Очерки по методике преподавания русского и родного языков в татарской школе. – М., 1952.

Жинкин Н.И. Механизмы речи. – М., 1958.

Жуковская О.А., Шаповалова Т.А. Изучение словообразования в восьмилетней школе. – М., 1983.

Зәкиев М.З. Синтаксис //Татар грамматикасы. Т. III. – Казан, 1995.

Зәкиев М.З. Туган телене укытуның кайбер гомуми дидактик принциплары һәм методлары //Татар телен укыту мәсьәләләре. – Казан, 1975.

Зәкиев М.З. 70 нче елларда татар лингводидактикасының үсеше //Туган телне укыту мәсьәләләре.–Казан, 1981.

Ибраһимов Г. Татар телен ничек укытырга? – Казан, 1919.

Курбатов Х.Р. Татар теленең алфавит һәм орфография тарихы. – Казан, 1960.
Мифтахов Б.М. Татар телен укыту методлары һәм алымнары. – Казан, 1983.
Методика преподавания русского языка /Под ред. М.С.Соловейчик. – М., 1988.
Николаева Т.М. Лингвистика текста. – М., 1978.
Сайкин Ш.Р. Синтаксик төзелмәләрнең аерымлануы, аның кыен очраклары. – Казан, 1980.
Сафиуллина Ф.С. Текст төзелеше. – Казан, 1993.
Сафиуллина Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология (югары уку йортлары студентлары өчен). – Казан, 1999.
Татар урта мәктәпләре өчен татар теленнән программа (V – XI сыйныфлар). – Казан, 1996.
Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясе. – Казан, 1978.
Фазлуллин М.Ә. Орфография нигезләре. – Казан, 1930.
Фазлуллин М.Ә. Татар теле методикасы. – Казан, 1954.
Федоренко Л.П. Принципы обучения русскому языку. – М., 1973.
Хаков В.Х. Мәктәптә стилистиканы өйрәнү. – Казан, 1970.
Хангилдин В.Н. Татар теле грамматикасы. – Казан, 1959.
Хуҗиәхмәтов Ә.Н. Педагогика. – Казан, 2000.
Хәлимова М.К. Югары классларда татар теле һәм әдәбияты дәресләре. – Казан, 1984.
Шакирова Л.З. Основы методики преподавания русского языка в татарской школе. – Казань, 1999.
Әхәтов Г.Х. Хәзерге татар теленең лексикологиясе. – Казан, 1979.
Җәләй Л. Татар теленең орфоэпик нигезләре. – Казан, 1953.

Программа составлена в соответствии с требованиями ФГТ (Приказ Минобрнауки РФ от 16.03.2011 №1365) и с учетом рекомендаций Минобрнауки РФ от 22.06.2011 № ИБ-733/12 по формированию ОПОП послевузовского профессионального образования для обучающихся в аспирантуре.

Авторы: Ф.Ф. Харисов, профессор кафедры татарского языка и методики преподавания; профессор Ч.М. Харисова, профессор кафедры татарского языка и методики преподавания

Рецензенты: Р.А. Юсупов, доктор филологических наук, академик АН РТ, профессор кафедры татарского языка и методики преподавания; М.М. Шакурова, кандидат филологических наук доцент.

Программа одобрена на заседании Учебно-методической комиссии Института филологии и межкультурной коммуникации КФУ от 19 марта 2014 года, протокол № 6.

# Татар телен чит тел буларак укыту методикасы
## П р о г р а м м а

### Гомуми мәсьәләләр

Татар телен чит тел буларак укыту методикасының өйрәнү предметы һәм бурычлары. Рус мәктәбендә татар теле укытуның максатлары һәм бурычлары.

Белем бирү стандарты. Аның максатлары. Татарстан мәктәпләрендә татар телен дәүләт теле буларак укыту эчтәлегенә куела торган таләпләр минимумы.

Программалар һәм дәреслекләр. Аларның эчтәлеге.

Белем бирү эчтәлегенең юнәлешләре.

Рус мәктәбендә татар теле укыту методикасының философия, психология, психолингвистика, педагогика (дидактика), тел белеме, рус теле, социолингвистика, чит телләр һ.б. фәннәр белән бәйләнеше.

Укыту эчтәлегенә караган кайбер мәсьәләләр. Тел чараларының һәм сөйләм эшчәнлегенең үзара мөнәсәбәте. Укыту эчтәлегенең телгә караган яклары (фонетика, лексика, грамматика). Сөйләм осталыгы һәм сөйләм күнекмәләре. Телгә өйрәтүнең культурологик аспекты.

Укыту предметының милли төбәк компоненты. Бу төшенчәнең асылы. Милли төбәк компонентының эчтәлеге.

Уку процессын оештыруның төп формасы буларак дәрес. *Дәреснең формалары:* дәрес-иҗат, дәрес-хезмәт, дәрес-аралашу, дәрес-дуслык, дәрес-очрашу, дәрес-концерт, дәрес-әңгәмә, катнаш дәрес, дәрес-түгәрәк өстәл, дәрес-остаханә, дәрес-викторина, дәрес-уен һ.б. *Дәреснең төп атрибутлары:* уку елы, уку көне, уку атнасы, чирек, каникул, тәнәфес, расписание һ.б. *Дәрес типлары:* сөйләм күнекмәләрен камилләштерү дәресе, сөйләм осталыклары үстерү дәресе һ.б. *Дәрес төзелеше:* башлау, төп өлеш, йомгаклау. *Дәрес төрләре:* яңа белем бирү, ныгыту, йомгаклау, тикшерү һ.б. дәресләр.

Рус һәм башка милләт вәкилләрен татар теленә өйрәтү тарихы. XVI йөздә язылган беренче русча-татарча кулъязма сүзлек. Галим һәм дәүләт эшлеклесе В.А.Татищев, 1 нче Казан гимназиясе директоры М.И.Веревкиннарның татар телен укытуны оештырудагы хезмәте. П.Рычков, М.Габдрахманов сүзлеге, М.Котельников сөйләүнамәсе, гимназиядә татар сыйныфы ачу турында Екатерина II нең указы. Мәгърифәтче Хәлфиннар Сәгыйть, Исхак һәм Ибраһим династиясенең бу өлкәдәге эшчәнлеге.

XX гасырда татар телен укытуга багышланган дәреслекләр, кулланмалар, сөйләүнамәләр (И.Гиганов, А.Троянский, А.Казем-Бек, И.Березин, А.Архангельский, Г.Ваһапов, М.Салихов һ.б.). Күренекле татар мәгърифәтчесе Каюм Насыйриның «Кыскача татар нәхүе», «Фәвакиһел җөләса фил әдәбият» һ.б. хезмәтләре.

XX гасырның 20-30 нчы елларында татар телен башка милләт вәкилләренә өйрәтүнең активлашып китүе (М.Х.Корбангалиев, Р.С.Газизов, З.Бәдыйгуллин, И.Кулиев һ.б.). 30 нчы елларда тел сәясәтенең кискен үзгәрә башлавы: телләрне һәм мәдәниятләрне бетерүгә юнәлдерелүе.

XX гасырның 90 нчы еллар башында бу проблеманың яңа сулыш алуы: «Татарстан халыклары телләре турында» гы закон (1992), «Татарстан Республикасы халыклары телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү турында» гы дәүләт программасы һәм башка норматив документлар.

Бүгенге көндә уку йортларында бу мәсьәләнең куелышы һәм чишелеше.

Гамәлдәге программалар, дәреслекләр, фәнни-методик хезмәтләр, кулланмалар, үзөйрәткечләр, сүзлекләргә характеристика (Ф.Ә.Ганиев, Ф.С.Сафиуллина, К.Р.Галиуллин, А.Ш.Әсәдуллин, Р.А.Юсупов, Ф.Ю.Юсупов, Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова һ.б.).

Татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәтү, И.Гиганов, И.Хәлфин, А.Троянский, А.Казем-Бек хезмәтләре. Каюм Насыйриның бу юнәлештәге эшчәнлеге.

XX гасырда яшәп иҗат иткән М.Х.Юнусов, В.А.Богородицкий, Н.К.Дмитриев, В.М.Чистяков, М.Х.Корбангалиев, Р.С.Газизов хезмәтләре. Шулай ук ике телнең чагыштырма типологиясенә зур өлеш керткән галимнәрдән Ә.М.Ахунҗанов, М.З.Зәкиев, Р.А.Юсупов, З.М.Вәлиуллина, Л.К.Бәйрәмова, Ф.С.Сафиуллина, Ф.Ф.Харисов һ.б.

Татар-рус лингводидактик типологиясе нигезләре. Татар-рус телләренең чагыштырма типологиясенә характеристика. Тел бүлекләренә караган охшаш һәм аермалы яклар, татар теленә чит тел буларак өйрәтүдә аларны белүнең әһәмияте.

Татар теле паспорты. Аны рус теле паспорты белән чагыштыру.

## Укытуның методологик нигезләре

*Лингвистик нигезләр.* Татар теленең методика белән тыгыз бәйләнеше (В.А.Богородицкий, М.Х.Корбангалиев, Р.С.Газизов, М.З.Зәкиев һ.б.).

Татар теле укыту методикасының теоретик нигезләрен билгеләүдә тел белеменең тоткан урыны. Татар һәм рус телләренә хас булган охшаш һәм аермалы якларны искә алу. Материалның эчтәлеге һәм характерының тел белеме аша белдерелүе, татар теле методикасының лингвистика фәне белән тыгыз мөнәсәбәттә булуы. Сөйләмдә куллану үзенчәлекләреннән чыгып, тел фактларын үзара бәйләнештә өйрәнү. Тел күренешләрен аралашу максатыннан чыгып, ситуатив-тематик принцип нигезендә үзләштерү.

*Лингвистик принциплар:* системалылык, һәм аңа бәйле булган комплекслылык, функциональ – семантик һәм культурологик принциплар.

Татар һәм рус телләренең үзара бәйләнеше, аның ике яклы икетеллелекне үстерүдәге роле. Рус укучыларына татар теле өйрәткәндә, бу телләргә хас булган охшаш һәм аермалы якларны куллану ысуллары.

## Психологик һәм психолингвистик нигезләр

Тел һәм фикерләү берлеге, фикерләү һәм сөйләмнең үзара мөнәсәбәте. Фикерләүнең белемгә нигезләнгән булуы. «Дәвамлы» һәм «кыска вакытлы» хәтер мәсьәләсе. Эчке һәм тышкы сөйләм. Психологиядә «тел» һәм «сөйләм» төшенчәләрен аерып карау, аның рус укучыларын татар сөйләменә өйрәтүдәге әһәмияте.

Сөйләм эшчәнлеге турында гомуми мәгълүмат. Яшь үзенчәлегенең укыту һәм тәрбия эшенә мөнәсәбәте. Сөйләм барлыкка килү һәм аны кабул итү механизмнары. Акыл эшчәнлеген этаплап формалаштыру теориясе (Г.Я.Гальперин, Д.Б.Эльконин һ.б.).

*Психологик принциплар:* укуга карата кызыксыну уяту, укучыларның шәхси сыйфатларын, яшь үзенчәлекләрен искә алу. Аларның татарча сөйләшергә өйрәтүдәге әһәмияте.

## Дидактик нигезләр

Дидактика турында гомуми мәгълүмат. Ян Амос Коменскийның «Бөек дидактика» (1657) исемле хезмәтендә бу проблеманың куелышы. Татар телен чит тел буларак укыту методикасының педагогика фәне белән бәйләнеше. Аның дидактик принципларга таянуы (М.А.Данилов, Б.П.Есипов, Г.В.Рогова, Л.З.Шакирова, А.Ш.Әсәдуллин, Ф.Ф.Харисов һ.б.).

*Дидактик принциплар:* фәннилек, системалылык һәм эзлеклелек, теорияне практика белән бәйләп укыту, аңлылык һәм активлык, аңлаешлылык һәм көч җитү, тәрбияви һәм үстерешле укыту, күрсәтмәлелек.

*Методик принциплар:* аралашу (коммуникатив), ситуатив-тематик, туган тел (рус теле) үзенчәлекләрен исәпкә алу принциплары. Аларның татар телен чит тел буларак укыту методикасы үзенчәлекләрен чагылдыруы.

*Татар теленә өйрәтү методлары:* туры (натураль), тәрҗемә итү, катнаш, аңлы-гамәли, интенсив, аңлы-чагыштыру һ.б.

*Татар теленә өйрәтү алымнары:* чагыштыру, сурәтләү, күзәтү һ.б.

**Татар теленә өйрәтү чаралары:**

♦ программа, дәреслек, кулланма һәм дидактик материаллар, техник чаралар;

♦ укытуның метод һәм алымнары;

♦ укыту-тәрбия эшенең нигезен тәшкил итә торган оештыру чараларыннан дәресләр, төрле характердагы эшләр, экскурсияләр, мөстәкыйль эшләр һ.б.

*Төп* (программа, дәреслек һ.б.) һәм *ярдәмче* (кулланмалар, журналлар, техник чаралар, төрле әйберләр, рәсемнәр, уенчыклар, таратма материаллар һ.б.) *чаралар.* Телгә өйрәтүдә заманча чаралардан файдалану (видеомагнитофон, компьютер).

**Сөйләм эшчәнлеге төрләре**

Сөйләм эшчәнлеге турында гомуми мәгълүмат. Аның *төрләре:*

♦ рецептив төрләре – тыңлап аңлау, сөйләү;

♦ продуктив төрләр – уку, язу;

*Формалары:*

♦ телдән – тыңлап аңлау, сөйләү;

♦ язма – уку, язу.

Аралашу вакытында сөйләм эшчәнлеге төрләренең үзара бәйләнеше. Тел материалы уртак булса да, һәр төрнең үзенчәлеген искә алып төзелгән күнегүләр системасы.

**Тыңлап аңлауга өйрәтү**

Тыңлап аңлауның аралашу вакытындагы роле. Укытуның төрле этабында (мәктәпкәчә белем бирү, башлангыч белем бирү, гомуми урта белем бирү) бу төрнең тоткан урыны, психологларның тыңлап аңлауга караган хезмәтләре (Л.С.Выготский, Н.И.Жинкин, И.А.Зимняя, А.А.Леонтьев). Сөйләмне телдән аңлауның *этаплары:*

♦ аерым фрагментларны гына аңлау;

♦ сөйләм эчтәлегенә төшенү;

♦ сөйләмнең мәгънәсенә тулысынча төшенү.

Тыңлап аңалуның сөйләү, уку һәм язу белән бәйләнеше.

Сөйләмнең мәгънәсенә төшендергәндә оештырыла торган уеннар, төрле хәрәкәтләр һәм паралингвистик чараларның (интонация, жест, мимика), шулай ук синоним һәм антоним сүзләрнең әһәмияте. Техник чаралардан файдалану.

Татарча тыңлап аңлауның нәтиҗәлелеген күтәрүдә күнегүләр системасына һәм укытучы сөйләменә караган таләпләр.

Укучыларның тыңлап аңлау күнекмәләренә ия булуын тикшерү юллары.

**Сөйләүгә өйрәтү**

Сөйләү – аралашуның аерылгысыз өлеше. Чит телдә сөйләүнең психологик табигатенә багышланган фәнни әдәбият. Бу проблемага күренекле психологларның (Л.С.Выготский, П.П.Блонский, Н.И.Жинкин, Б.В.Беляев), методистларның (Е.И.Пассов, Е.В.Коток, Г.В.Рогова, И.Н.Верещагина) карашы.

Лингвометодикада аралашуның *төрләре:*

♦ прецептив (аралашучылар бер-берсен күреп, хәбәрне интуитив рәвештә кабул итәләр);

♦ интерактив (аралашучылар бер-берсенә тәэсир итәләр, йогынты ясыйлар);

♦ коммуникатив (аралашучылар фикер алышалар, сөйләшәләр).

Сөйләм эшчәнлегенең башка төрләренә сөйләүнең мөнәсәбәте.

Сөйләүнең өч *фазасы:*

♦ максатны ачыклау;

♦ фикерне тел формалары ярдәмендә рәсмиләштерү;

♦ сөйләмне тавыш белән белдерү;

Сөйләүгә өйрәтүнең ишетү, күрү, вербаль һәм вербаль булмаган терәкләргә нигезләнүе.

Телдән сөйләмнең ике формада (диалог һәм монолог) башкарылуы. Диалогик һәм монологик сөйләм үзенчәлекләре.

***Диалогик*** (кара-каршы) ***сөйләмгә өйрәтү.*** Диалог үрнәкләре (модельләр). Өйрәтү этаплары:

♦ *рецептив* (үрнәкне тыңлау һәм аңлау);

♦ *репродуктив* (ситуация эчендә үзгәртеп, диалогик үрнәкне хәтердән охшатып сөйлү);

♦ *конструктив* (чагыштырмача ирекле сөйләм);

Ситуатив-тематик принцип нигезендә төзелгән күнегүләр системасы.

